**Азнакай муниципаль районы**
**Урсай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Урсай авылы № 151 «26» май 2025 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Советының 2016 елның 17 июнендэге 35 номерлы карары белән расланган (18.11.2016 №43, 06.10.2017 №70, 30.01.2018 №88, 19.02.2020 №168, 18.04.2020 №174,11.10.2021 №38, 05.04.2023 №82, 22.09.2023 №95, 23.01.2024 №108, 27.11.2024 №134 карарлар редакциясендә) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2025 елның 20 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Урсай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Советының 2016 елның 17 июнендэге 35 номерлы карары белән расланган 18.11.2016 №43, 06.10.2017 №70, 30.01.2018 №88, 19.02.2020 №168, 18.04.2020 №174,11.10.2021 №38, 05.04.2023 №82, 22.09.2023 №95, 23.01.2024 №108, 27.11.2024 №134 карарлар редакциясендә) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәнең 6 бүлегенең 2.16 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) «а» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле җөмләне өстәргә: «Шул ук вакытта муниципаль молкәт «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законда һәм (яисә) башка федераль законнарда, һәм (яисә) гавами сервитутта каралган чикләүләргә дучар ителергә мөмкин.»;

б) «ж» пунктчасының бишенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис З.Х.Рахимьянова